ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/14

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре участок сайлау комиссияләренең резерв составларына өстәмә билгеләү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү турында

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ санлы Федераль законның 27 маддәсе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2012 елның 5 декабрендәге 152/1137-6 санлы карары белән расланган участок комиссияләренең составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссиясе составлары резервыннан яңа әгъза билгеләү Тәртибенең 12 пунктына, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2010 елның 07 июнендәге 59/418 санлы карары белән расланган алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның календарь-методик планы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә участок сайлау комиссияләренең резерв составларына өстәмә билгеләү өчен кандидатуралар турында тәкъдимнәрне 1-3 нче кушымталарга нигезләнеп кертергә.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә җибәрергә.

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев